ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ
АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

**КАРАР**

22 ноябрь 2024 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылы гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:
   - торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторга асылмалы җайланма сатып алу)
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.